| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

19.05.2017 Казан ш. № 1122-р

**Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен үзгәртү Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 07.08.2014 № 1620-р карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында” 30.04.2014 № 288 карарына туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм газ бүлү челтәрләренә милек хокукын раслаучы документлар нигезендә, һәм «РКЦ «Земля» АҖ башкарган документациягә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында” 07.08.2014 № 1620-р карары (алга таба - № 1620-р Карар) белән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә (Комлы Кавал авыл җирлеге, Комлы Кавал ав., Авангradная ур.) урнаштырылган, «Газпром трансгаз Казань» (ЭПУ «Приволжскгаз»)

милкендә булган, 252 кв.м гомуми территориядәге 63 м озынлыктагы, 22850 инвентарь номерлы газүткәргечнең 16:24:090103:220, 16:24:090103:221 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендәге (06.07.2015да 16:24:090103:188 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән ясалган) өлеше демонтажлану сәбәпле саклау зонасын бетерергә.

2. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖның № 140-2016, 18.10.2016 килешүе нигезендә «РКЦ «Земля» АҖ тарафыннан 2016 елның 15 декабреннән 16 декабренә кадәр әзерләнгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасы, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә (Комлы Кавал авыл җирлеге, Комлы Кавал ав., Аванградная ур.) урнаштырылган, «Газпром трансгаз Казань» (ЭПУ «Приволжскгаз») милкендә булган, 424 кв.м гомуми территориядәге 106 м озынлыктагы, 22850 инвентарь номерлы газүткәргечнең 16:24:090103:220, 16:24:090103:221, 16:24:090103:3, 16:24:090103:4 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендәге саклык зонасы чикләрен расларга.

3. №1620-р Карарның 2 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән һәм әлеге карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрләрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

4. «РКЦ «Земля» АҖ тарафыннан 2016 елның 15 декабреннән 16 декабренә кадәр әзерләнгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасы, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп, № 1620-р Карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, 951,043 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 3,804172 кв.км территорияне тәшкил иткән, инвентарь номеры әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән ЭПУ «Приволжскгаз» газ бүлү челтәренең (газүткәргечләрнең) «Граница» кадастр үзәге» ҖЧҖ тарафыннан 2013 елның 3 июненнән 2013 елның 13 декабренә кадәр әзерләнгән һәм «Газпром трансгаз Казань» тарафыннан 2013 елның 31 декабрендә килештерелгән территорияне

файдаланунының аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасы, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп саклау зоналары чикләрен расларга.»;

3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1 нче кушымтада 183 нчы юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 183 | 22850 | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Комлы Кавал авыл җирлеге, Комлы Кавал ав. | 6807,15 м | d=63 Түбән басым<br>d=110 Түбән басым<br>d=160 Түбән басым е | № 16:24-5:2001-1490.1 от 26.09.2001 |

2 нче кушымтада элек 16:24:090103:188 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан газүткәргеч өлешенә туры килгән 22850 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 22850 | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Комлы Кавал авыл җирлеге, Комлы Кавал ав. Авангардная ур. | Милек | | 16:24:090103:220<br>16:24:090103:221<br>16:24:090103:3<br>16:24:090103:4 | Торак Пунктлар җирләре | 424 кв.м (саклык зонасы мәйданы) | | Шәхси торак төзелеше өчен |

5. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖга тәкъдим итергә:

1) әлеге карарның 1, 2 пунктларында газүткәргечләрнең саклау зоналары турында төгәлләштерелгән белешмәне Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү чараларын күрергә;

2) әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән, элек 16:24:090103:188 кадастр номерлы җир кишәрлегендә (күрсәтелгән җир кишәрлекләре чсалган) булган җир асты газүткәргече өлеше демонтажлану сәбәпле 16:24:090103:220, 16:24:090103:221 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә булган чикләүләрнең туктатылуы турында белешмәне Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрына кертү чараларын күрергә;

3) әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән, 22850 инвентарь номерлы газүткәргечнең саклык зонасына кергән 16:24:090103:220, 16:24:090103:221, 16:24:090103:3, 16:24:090103:4 кадастр номерлы җир кишәрлекләренә булган чикләүләрне Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрына кертү чараларын күрергә;

4) әлеге карар кабул ителүгә 5 көн эчендә карарны, электрон формада әзерләнгән территорияне файдаланунының аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасын, әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән газүткәргечнең характерлы нокталары координаталары исемлеген беркетеп, әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән газүткәргеч өлешләренә

элек куелган саклау зоналары үзгәрү турында һәм әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән газүткәргеч өлешенә саклык зонасы кертелү турында белешмәне күчемсез милек бердәм дәүләт реестрына кертү өчен хокукларны регистрацияләү органына юлларга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир ресурслары идарәсе башлыгы Г.Э.Миндубаевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**